**Республика Татарстан**
**Совет Большенуркеевского сельского поселения Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге Советы**

---

**РЕШЕНИЕ** **с.Большое Нуркеево** **КАРАР**

**14 сентябрь 2018 ел** **№ 69**

**Референдум уздыруны инициацияләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Зур Нөркәй авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

"2019 елда Зур Нөркәй авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан һәм ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан, дүрт һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләрдән тыш, 200 сум күләмендә үзара салым җыюга һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә риза булырсызмы:

1) 1) җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру, шул исәптән:

- Сабантуй бәйрәмен үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

2) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен тикшереп тору, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру, шул исәптән:

- Зур Нөркәй авылы урамнарын яктырту челтәрләрен карап тоту һәм аларга техник хезмәт күрсәтү

- махсуслаштырылган техниканы тоту - «Беларус-82.1» тракторы (ягулык-майлау материаллары сатып алу, машина йөртүче хезмәтләре өчен түләү);

- триммер сатып алу;

- Зур Нөркәй авылында урамнарның исемнәре һәм йортларның номерлары күрсәтелгән күрсәткечләрне урнаштыру;

- Зур Нөркәй авылында көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны вакытлыча җыю;

3) Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту, шул исәптән: - Зур Нөркәй бистәсендә зират территориясен киртәләү өчен төзелеш материаллары сатып алу;

ӘЙЕ ЮК».

Әлеге карар мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

Зур Нөркәй авыл җирлеге башлыгы Р.М.Гайсин